**Сәгатьләр саны:** 105

**Барысы** 35 атна ;**атнага** 3 сәгать.

**7нче сыйныфта татар теле дәресләренең календарь-тематик планы**

| **№** | **Үткәрү вакыты** | | **Бүлек** | **Дәреснең темасы** | **Укучылар эшчәнлегенә характеристика яки укыту эшчәнлеге төрләре** | **Бәяләү материаллары** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **План** | **Факт** | | | | |
| 1. | | | | Туган телем- иркә гөлем .Кереш дәрес. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү,танып белү активлыгын үстерү | |
| 2. | | | | 6нчы сыйныфта үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау. | Анализ, синтез, гомумиләштерү, системалаштыру һәм нәтиҗә ясау күнекмәләрен камилләштерү | |
| 3. | | | | Исем сүз төркемен кабатлау. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | |
| 4-5 | | | | Кабатлау | Фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп изложение язуны камилләштерү | |
| 6. | | | | Сыйфат сүз төркемен кабатлау. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | |
| 7. | | | | Сан сүз төркемен кабатлау. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | |
| 8 | | | | Б.с.үстерү.Эш кәгазьләре. | Дәреслек белән эшли белү. | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | (гариза, ышаныч кәгазе) | Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 9. | | | | Алмашлык сүз төркемен кабатлау. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | |
| 10. | | | | Рәвеш сүз төркемен кабатлау. | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | |
| 11. | | | | Фигыль сүз төркеме.Мәгънәсе, сораулары | Үз-үзеңә контроль ясау | |
| 12. | | | | Фигыльнең нигезе. | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 13. | | | | **Диктант №1**<br>**Тургай** | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | **Диктант** |
| 14. | | | | Хаталар өстендә эш<br>Фигыльнең барлык-юклык формасы. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 15. | | | | Фигыль юнәлешләре. | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | белү. | |
| 16. | | | | Фигыль юнәлешләрен билгеләүдә кыен очраклар | Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 17. | | | | Фигыль юнәлешләрен | Логик фикер йөртү, чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау | |
| 18 | | | | **Сочинение “ Минем яраткан эшем”** | Фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп сочинение язуны камилләштерү | |
| 19 | | | | Хаталар өстендә эш<br>Фигыль төркемчәләре. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 20-21. | | | | Затланышлы фигыльләр.Боерык фигыльнең мәгънәсе, зат-сан белән төрләнеше. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 22. | | | | Боерык фигыльнең дөрес интонация һәм басым белән кулланылышы. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 23 | | | | **Диктант №2**<br>**Ләкләк.** | | |
| 24. | | | | Б.с.үстерү. Боерык фигыльләр кертеп хат язу | Хат язарга өйрәнү | |
| 25. | | | | Хикәя фигыль. Хәзерге заман хикәя фигыль. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | үстерү | |
| 26. | | | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең мәгънәләре | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 27. | | | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең мәгънәләре | Фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп хикәя язуны камилләштерү | |
| 28. | | | | Үткән заман хикәя фигыль. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 29. | | | | Үткән заман хикәя фигыльнең мәгънәләре | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 30. | | | | Киләчәк заман хикәя фигыль. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 31. | | | | Киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәләре | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 32. | | | | Бсү Хикәя фигыльнең төрле заманнарыннан файдаланып әдәби герой турында сөйләү. **Сочинение .** “Минем яраткан әдәби героем” | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | **Сочинение** |
| 33. | | | | Шарт фигыль.Мәгънәсе, формасы, зат-сан белән | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | төрләнеше. | үстерү | |
| 34. | | | | Шарт фигыльнең җөмләдә кулланылышы | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 35. | | | | Шарт фигыльнең теләкне һәм үтенечне белдерү формалары | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 36. | | | | Затланышлы фигыльләрне кабатлау. | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 37. | | | | Затланышлы фигыльләрне кулланып, хикәя төзү.БСҮ. | Фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп хикәя язуны камилләштерү | |
| 38. | | | | Затланышсыз фигыльләр. Сыйфат фигыль. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 39. | | | | Хәзерге заман сыйфат фигыль. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 40. | | | | Үткән заман сыйфат фигыль. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 41. | | | | Киләчәк заман сыйфат фигыль. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 42-43 | | | | **Изложение №1** **Ун сумлык «маҗара».** | Фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп изложение язуны камилләштерү | **Изложение** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 44. | | | | Хаталар өстендә эш<br>Хәл фигыль.Аның мәгънәсе,формалары. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 45. | | | | Хәл фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы һәм дөрес  язылышы. | Фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп хикәя төзүне камилләштерү | |
| 46. | | | | Диалог төзү.БСҮ. | Фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп диалог төзүне камилләштерү | |
| 47. | | | | Текстны русчадан татарчага тәрҗемә итү һәм эчтәлеген сөйләү | Татар теле һәм рус телендә сүзләр бәйләнешенең  уртак һәм аермалы якларын таба белү | |
| 48. | | | | Исем фигыль.Мәгънәсе,форма-сы, сөйләмдә кулланылышы. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 49. | | | | Исем фигыльнең исемгә әйләнү очраклары. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 50. | | | | Бсү. Сүзлекләрдә исем фигыль | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 51 | | | | **Контроль диктант№3 Песнәк** | | **Диктант** |
| 52. | | | | Хаталар өстендә эш<br>Инфинитив. Мәгънәсе, формалары. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 53. | | | | Инфинитивның сөйләмдә | Татар теле һәм рус телендә | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | дөрес кулланылышы һәм дөрес язылышы | инфинитивның уртак һәм аермалы якларын таба белү | |
| 54 | | | | Затланышсыз фигыльләрне кабатлау | Татар теле һәм рус телендә сүзләр бәйләнешенең уртак һәм аермалы якларын таба белү | |
| 55. | | | | Ярдәмче фигыльләр,аларның кулланылышы. | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 56. | | | | Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыль ролендә йөрүе. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| | | | | | | |
| 57. | | | | Фигыльләрнең ясалышы. | Дәреслек белән эш итә белү,танып белү активлыгын үстерү | |
| 58. | | | | Фигыльләрнең төрле җөмлә кисәкләре булып йөрүе. | Дәреслек белән эш итә белү,танып белү активлыгын үстерү | |
| 59. | | | | Б.с.үстерү.Эш кәгазьләре(акт төзү) | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 60-61. | | | | Фигыльләргә морфологик анализ ясау. | Язма күнегүләр эшләү | |
| 62. | | | | Фигыль турында | Язма күнегүләр эшләү | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | үткәннәрне кабатлау | | |
| 63.-64 | | | | **Изложение №2**<br>**Тәрбияле бала.** | Үз-үзеңә контроль ясау | **Изложение** |
| 65 | | | | Хаталар өстендә эш<br>Татарчадан русчага<br>Һәм русчадан татарчага<br>тәрҗемә итү күнегүләре. | Язма күнегүләр эшләү | |
| 66. | | | | Аваз иялтемнәре. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 67. | | | | Аваз иялтемнәренең сүз ясауга<br>нигез булып торуы. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 68. | | | | Аваз иялтемнәренә морфологик<br>анализ ясау. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 69. | | | | **к**абатлау | Үз-үзеңә контроль ясау | |
| 70. | | | | Хәбәрлек сүзләрнең формалары,<br>җөмләдә кулланылышы. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 71. | | | | Хәбәрлек сүзләргә морфологик<br>анализ ясау тәртибе | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгәндә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 72. | | | | Хәбәрлек сүзләр турында үткәннәрне<br>кабатлау. | Биремнәрне үтәү | |
| 73. | | | | **Диктант №4**<br>**Чәчәк -күбәләк** | Үз-үзеңә контроль ясау | **Диктант** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 74. | | | | Хаталар өстендә эш<br>Бәйлекләр. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 75. | | | | Бәйлекләрнең төркемчәләре. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 76. | | | | Бәйлек сүзләр. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 77. | | | | Бәйлекләргә морфологик анализ ясау. | Язма күнегүләр эшләү | |
| 78. | | | | Бәйлекләрне кабатлау. | Язма күнегүләр эшләү | |
| 79. | | | | Хаталар өстендә эш<br>Теркәгеч. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 80. | | | | Теркәгечләрнең төркемчәләре. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 81. | | | | Теркәгеч сүзләр. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 82. | | | | Теркәгечләрнең дөрес язылышы. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 83. | | | | Теркәгечләргә морфологик анализ ясау. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 84. | | | | Теркәгечләрне кабатлау. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 85. | | | | **Сочинение.**<br>**”Бәйрәм белән котлау”** | Игътибарлылык һәм кызыксынучанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 86- | | | | Хаталар өстендә эш | Фикер йөртү элементлары | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 87. | | | | Үткәннәрне кабатлау | кертеп, гади яки катлаулы план төзеп изложение язуны камилләштерү; | |
| 88. | | | | Модаль сүз төркемнәре.Кисәкчә. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 89. | | | | Кисәкчәләрнең төркемчәләре. | Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү | |
| 90.-91 | | | | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 92. | | | | Кисәкчәләргә морфологик анализ ясау. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 93. | | | | Күнегүләр эшләү | Үз-үзеңә контроль ясау | |
| 94. | | | | Б.с.үстерү.Эш кәгазьләре Автобиография язу ни өчен кирәк? | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 95. | | | | Ымлыклар. Төркемчәләре. | Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү, танып белү активлыгын үстерү | |
| 96 | | | | Ымлыклар янында тыныш билгеләре. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 97. | | | | Ымлыкларга морфологик анализ ясау. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 98. | | | | Ярдәмлек сүз төркемнәрен кабатлау. | Язма һәм телдән күнегүләр эшләү | |
| 99- | | | | Контроль диктантка әзерлек | Дәреслек белән эшли белү. Игътибарлылык һәм кызыксыну чанлыкны үстерү. Биремнәрне үтәгән дә үз эшчәнлегеңне планлаштыра белү. | |
| 100. | | | | **Контроль диктант №5** | Үз-үзеңә контроль ясау | **Диктант** |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **Укытучыма рәхмәт** | | |
| 101-102. | | | | Хаталар өстендә эш<br>Морфология буенча үткәннәрне кабатлау | | |
| 103. | | | | Кабатлау дәресе | | |
| 104 | | | | Кабатлау дәресе | | |
| 105 | | | | Йомгаклау дәресләре. | | |

**7нче сыйныф өчен**
**ДИКТАНТ ТЕКСТЛАРЫ**

## №1

## Тургай

...Кайсы сайрар кош туган якларына бүтәннәрдән иртәрәк кайтып төшә? Белмәсәгез, үзем әйтәм: тургай! Нәрсә генә кирәк ул кошкайга? Басуларда кар астыннан песи табаны тикле генә җир ачылдымы, аңа шул җитә. Ул назландырып тормас, кайтыр да кунар. Сабан чәчүе башланганчы ук, кызарып кояш чыккан мизгелләрдә кем безне шатлык җырлары белән каршы ала? Әлеге дә баягы шул тургай инде, тургай! Безнең якларның кайсы кошы җәенә икешәр оя бала чыгара? Кайсысы, башкалар җылы якларга китеп беткәч тә, көз башына тикле туктамыйча сайрый? Һаман да шул челтер-челтер көмеш тавыш — рәхмәт төшкере тургай! Менә син иртә торуларыңа басу тарафларына колак сал. Сайрыймы тургайларың, күпме алар? Сайрасалар, күп булсалар — син бәхетле. (105 сүз.) *(Гомәр Бәширов)*

## №2

## Ләкләк.

Сезнең ләкләк турында әкият тә, җыр да, шигырь дә ишеткәнегез бардыр, әлбәттә. Нәкъ менә шул ләкләк инде авыл янындагы болында беркемнән дә курыкмыйча йөри, үзенең зур оясын авыл өе түбәсендә чыбык-чабык, ботаклардан ясый.

Ак ләкләкнең — бу шактый зур кошның — кешеләр белән кайчан дуслашып китүен һичкем хәтерләми. Ләкин кешеләр

шушы гүзәл кош белән дуслыкның кадерен беләләр, аларның тынычлыгын бик тырышып саклыйлар.

Ләкләкләр сезнең өй түбәсенә бер мәртәбә оя ясасалар, алар яз саен шунда очып киләчәк. Ояда озын сыйраклы өч яки биш ләкләк бәбкәсе булачак. Алар кешеләргә ышанып карап торалар, ата-аналарының аудан кайтканын көтәләр, җылы җилдә башларын чак-чак кына кырын салып торалар. Ә ата-аналары аларга бака, тычкан, кәлтә, төрле бөҗәк ташып тора.

Көзгә таба ләкләк бәбкәләре үсеп җитә, көчле зур кошка әверелә, аннан көньякка очып китә. Ә кешеләр язын үзләренең ышанычлы дусларын яңадан көтәләр. (135 сүз)

*«Кем ул? Нәрсә ул?» китабыннан*

**Бирем**

**Ике алмашлыкка морфологик анализ ясарга.**

## №3

## Песнәк

Кышның салкынча гына көнендә ачык форточкадан песнәк очып керде. Фәнияр кош-кортларны бик ярата иде, песнәккә чиксез шатланды. Песнәк тә, җылы өйгә эләгүенә һәм куркытучы кеше булмаганга, өйдән тиз генә чыгып китәргә ашыкмады. Ә әнисе кайтып кергәч, Фәнияр форточканы яптырып куйдырды. Песнәкне бик тә өендә калдырасы килде аның. Ә песнәк өйгә ияләшергә теләмәде. Биргән ризыкларга да кагылмады. Тәрәзәгә канатларын бәрә-бәрә, тышка, иркенгә омтылды. Фәнияр аны читлеккә яптырды. Ләкин ирек кошы тар читлекне үз итмәде. Боекты, саргайды. Ничектер тынып калды. Тәрәзәнең тышкы ягында чагында чырык-чырык сайрап туймаган кош, өйгә кергәч, тавышын да чыгармады. Шуннан соң Фәнияр, тәрәзәне ачтырып, аны тышка чыгарып җибәрде. (100 сүз.) *(Фәнис Яруллин)*

## №4

## Чәчәк-күбәләк

Ирексездән Булатның куллары чәчәккә үрелделәр. Ләкин ул килеп кагылуга, чәчәк зур кызыл күбәләк булып күтәрелде дә икенче бер куакка күчеп утырды. Утыруы булды, яңадан шундый ук гөләп чәчәгенә әверелде. Булат тагын аңа якынлашты, тагын сакланып кына кулларын сузды. Гөләп куагы салмак кына чайкалып куйды, тураеп, башын читкә борды, һәм тылсымлы чәчәк, тагын куактан аерылып, күбәләк булып очты.

Булат, сихерләнгән кебек, аның артыннан йөгерде. Чәчәк-күбәләк, куактан куакка, агачтан агачка куныц, бик озак очып оарды, үлән асларына кереп качты, биеккә-биеккә, зәңгәр һа-валарга күтәрелде, тагын түбән төште, тагын урман аланнарын ". йлатып, Булатны үчектереп йөрде. Булат тәмам хәлдән тай--ы, киселгән агач төбенә утырды. Ә күбәләк, әйтерсең шуны гына көткән, Булатның нәкъ картлысына ук килеп төште дә :-:унды... (113 сүз.) *(Габделхәй Сабитов)*

## Укытучыма рәхмәт№5

Гусаров фамилияле укытучыма гомер буе рәхмәт укыйм. Ул бездә аш-су остасы һөнәрен хөрмәтләргә, олыларга кирәк дигән хакыйкатькә ышаныч тәрбияләде. Бөтен гомерен кулинариягә багышлаган бу мөхтәрәм кеше бик күп аш төрләрен белә, аның хәтта куллары да нинди ашка күпме тәмләткеч, күпме су салырга икәнен үлчәүсез-нисез, төп-төгәл беләләр кебек иде. Гусаровның аш пешерүен күзәтеп торсаң, сабырлыгың кими, тизрәк шул ризыкны кабып карыйсың килә башлый иде.

Бу оста үз эшен, менә хәзер мин сезгә гаҗәеп бер могҗиза ясап күрсәтәм, дигән төсле, серле итеп башлап җибәрә, һәрчак мөлаем йөзен иҗат кешеләренә хас уйчанлык пәрдәсе каплый.

Пешекче алмаштырып куйгандай үзгәреп китә: гүя ул без күреп өйрәнгән гади аш пешерүче генә түгел, ә илаһи зат, рәссам, шагыйрь, композитор! (112 сүз.) *(Юныс Әхмәтҗанов)*

**1.БСҮ. Изложение.**

**Ун сумлык «мажара».**

Менә ничә сәгать инде алар карбыз бушата. Әстерхан якларыннан баржа белән килгән карбызларны машиналар ташып кына тора. Ә карбызлар эре, кайберләреңә колач та җитми, авыр үзләре. Андый-ларын икәүләп күтәрәләр. Акча бирәм, дигәч, малайлар бу эшкә дәррәү тотынганнар иде. Кайберәүләрнең гайрәте тиз шиңде. Надир белән янәшә баскан малай да, футбол тубы хәтле бер карбызны чәлеп, таю ягын карады. Ә Надир түзде, түзәргә тырышты. Хуҗалардан аласы ун сум акча тотты аны. Бик авырга килгәндә, әнисен сөендерер минутларны уйлап чыдады.

Әнисе эшсез калгач, аларның тормышлары авыр бара башлады. Шәл сатып алган акча да күпкә җитмәде. Бүген иртән Надир әнисенең көзге каршында басып торган чагын күрде. Менә ул авыр сулап колак алкаларын салды да кулъяулыгына төрә башлады. Шул чагында малай әбисеннән калган алкаларны соңгы тапкыр күрүен аңлады. Надирга әнисе дә, кашлары җем-җем итеп торган алтын алкалар да бик кызганыч булды. Әнисе өйдән чыгып киткәч тә тынычлана алмады. Мәктәпкә бармаска, акча эшләп әнисенә булышырга, дигән уй килде башына. (163сүз)

**БСҮ. Изложение.**
**Тәрбияле бала.**

Беркөнне Зиннәт урамнан акча янчыгы табып керде. Аның шатлыгы эченә сыймый иде. Бумажник эчендә байтак кына акча, блокнот һәм бер хәрби кешенең фоторәсеме дә бар.
Зиннәтнең күзләре шатлыгыннан ут шикелле яна, ә башында аның гаҗәеп матур уйлар йөри. Бу акчага тимераяк та, өр-

яңа велосипед та алып була. Әле аннан да артып калыр.
Әнисе рәсемне кулына алды. «Бу офицер фронтта үлгән булса кирәк. Бәлки ул немецларга каршы әтиең белән бергә сугышкандыр. Бу әйберләрне югалткан кеше хәзер бик кайгыра торгандыр. Улының соңгы рәсемедер бу», — диде.
Әнисенең бу сүзләреннән соң Зиннәт уйга калды. «Кемнеке икәнен белсәк, илтеп бирер идек», — диде ул.
Әнисе улының шундый җавабын баядан бирле көтә иде. Менә ул аны ишетте һәм улын кочаклап алды. Шуннан соң алар бу әйберләрнең хуҗасын эзләргә булдылар, чаттагы баганага белдерү ябыштырдылар.
Беркөнне аларның ишеген кемдер акрын гына шакылдатты, бүлмә эченә озын мыеклы бер абый килеп керде. Ул үзенең бумажник югалтканын әйтте һәм аның нинди икәнлеген сөйләп бирде. Әнисе шунда ук бумажникны абыйга сузды.
Мыеклы кеше әйберләрнең барысының да урынында икәнлеген күрде, рәхмәт әйтте һәм Зиннәтне үзләренә кунакка чакырды. Ул Зиннәтне кунак итте һәм аңа бер төргәк биреп җибәрде.
Зиннәт белән әнисе төргәкне ачып карадылар. Аның эченә күп кенә конфет һәм бумажниктагы акчалар салынган иде.
(199 сүз.) (А. Шамовтан)